ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ БИСТӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

04.09.2020 ел № 95-2

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлегенең архив фондларын формалаштыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Кызыл Бистә авыл җирлеге Уставының 5 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлегенең архив фондларын формалаштыру турындагы нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән соң икенче көнгә үз көченә керә.

3. Кызыл Бистә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

ТР Спас муниципаль районының
Кызыл Бистә авыл җирлеге башлыгы А.В. АВлиев

Татарстан Республикасы Спас
муниципаль районының Кызыл Бистә
авыл җирлеге Советы карарына
кушымта
« 04 » 09.2020 ел № 95-2

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ БИСТӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ АРХИВ ФОНДЛАРЫН ФОРМАЛАШТЫРУ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы (алга таба текст буенча - федераль закон), «Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлегенең архив фондын булдыру максатларында эшләнде.

2. Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр һәм терминнар:

- җирлекнең архив фондлары дигәндә җәмгыятьнең тарихи, фәнни, социаль, икътисадый, сәяси һәм мәдәни әһәмияткә ия булган, даими сакланырга тиешле һәм Россия Федерациясе Архив фондының состав өлеше булып торучы мәгълүмати ресурсларга кагылышлы Татарстан Республикасы халыкларының тарихи-мәдәни мирасының аерылгысыз өлеше булып торучы һәм җәмгыятьнең матди һәм рухи тормышын чагылдыра торган архив документларының барлыкка килгән һәм даими тулыландырыла торган җыелмасы аңлашыла;

- Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

## 2. Архив фондларын формалаштыру

3. Җирлекнең Архив фондлары район муниципаль архивында даими сакланырга тиеш.

4. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлегенең архив фондларын төзү Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан Спас муниципаль районының муниципаль архивы һәм аның оештыру-методик җитәкчелегендә килештерелгән срокларда гамәлгә ашырыла.

5. Җирлекнең архив фондларын сыйфатлы формалаштыру, архив документларын саклау срокларын үтәү максатларында җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, музейлар һәм китапханәләр:

5.1. Эш номенклатураларын район муниципаль архивына әзерлиләр һәм җибәрәләр;

5.2. даими һәм озак вакытлы (10 елдан артык) саклау эшләрен, шул исәптән шәхси составы буенча район муниципаль архивына төзиләр һәм тасвирлап бирәләр;

5.3. район муниципаль архивына сакланырга тиеш булмаган документларны юк итү турында актлар төзи һәм җибәрә;

5.4. җирлекнең архив фондлары документларына фәнни-белешмә аппаратын булдыралар һәм тулыландыралар;

5.5. архив документларының сакланышын тәэмин итәләр, шул исәптән шәхси состав буенча да, аларны саклау вакыты дәвамында.

6. Җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, Музейлар һәм китапханәләр җирлекнең архив фондларын формалаштыру өчен кирәкле финанс, матди-техник һәм башка шартларны тәэмин итәргә, архив документларын саклауның норматив таләпләренә җавап бирә торган бүлмәләрне бирергә бурычлы.

3. Документларны район муниципаль архивына тапшыру тәртибе

7. Җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, Музейлар һәм китапханәләрнең документлары, аларны вакытлыча саклау вакыты чыккач, район муниципаль архивына даими саклауга тапшырыла.

8. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитеты, муниципаль оешмалар билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә муниципаль архивларга сайлап алу, әзерләү һәм тапшыруны тәэмин итәләр. Архив документларын даими саклауга сайлап алу, әзерләү һәм тапшыру, шул исәптән аларны тәртипкә китерү һәм транспортлау белән бәйле барлык эшләр дә документларны тапшыручы органнар һәм оешмалар акчалары хисабына башкарыла.

9. Даими саклау документларын тапшыру, муниципаль район Хакимияте карары белен расланган план-графикка ярашлы, ведомство саклау сроклары чыккач, тиешле фәнни-белешмә аппараты белен тәртипле хәлдә башкарыла. Документларны даими саклауга вакытыннан алда тапшыру документларны югалту (юк итү) куркынычы янаганда, шулай ук җирлек башкарма комитеты үтенече буенча башкарылырга мөмкин.

10. Документларны вакытлыча саклау сроклары, муниципаль архив белән килешенеп, документларны практик куллану кирәк булган очракта, озайтылырга мөмкин.

11. Оешмалар эшчәнлегендә барлыкка килә торган типик идарә документлары исемлеге нигезендә, шәхси состав буенча документлар, хезмәткәрләрнең шәхси эшләре, хезмәт килешүләре, хезмәткәрләрнең шәхси карточкалары, хуҗалык кенәгәләре һ.б.) 75 ел дәвамында Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Башкарма комитетында, муниципаль оешмаларда саклана, аннары муниципаль районның муниципаль архивына саклауга тапшырыла.

12. Муниципаль оешмаларны үзгәртеп корганда архив документлары тәртипле хәлдә үзгәртеп корыла торган оешмаларның хокук дәвамчылары тарафыннан тапшырыла. Шул ук вакытта муниципаль оешмаларны әлеге оешмаларның милек рәвешләре үзгәргән очракта, архив документлары яңа барлыкка килгән оешмаларга-хокукый дәвамчыларга әлеге оешмалар һәм тиешле муниципаль архив арасындагы шартнамәләр нигезендә вакытлыча саклауга тапшырылырга мөмкин.

13. Җирлекнең җирле үзидарә органнарын, муниципаль оешмаларны бетергәндә, шәхси состав буенча документлар, шулай ук вакытлыча саклау вакыты чыкмаган архив документлары муниципаль районның муниципаль архивына саклауга тәртипле рәвештә керә.

14. Документларны даими саклауга кабул итү авыл җирлеге башкарма комитеты һәм муниципаль район башкарма архивы тарафыннан кабул итү-тапшыру акты белән рәсмиләштерелә.

15. Документлар белән бергә өч нөсхә опись тапшырыла, бер нөсхәсе авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.

4. Архив документларын куллану

16. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, музейлар һәм китапханәләр, тиешле архив документлары булса, билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән архив белешмәләрен яисә гражданнарны социаль яклауга бәйле архив документларының күчермәләрен түләүсез бирергә, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә ташламалар һәм компенсацияләр алырга тиеш.